**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 17 апреленнән №53-412

Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 14 декабрендәге 39-321 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хуҗа булуга һәм (яисә) файдалануга тапшырылырга тәгаенләнгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендәге күчемсез муниципаль мөлкәт исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм оешмаларга, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллanучы физик затларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 14 декабрендәге 39-321 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 13 декабрендәге 50-391 номерлы карары редакциясендә) расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хуҗа булырга һәм (яисә) файдалануга тапшырылырга тәгаенләнгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендәге күчемсез муниципаль мөлкәт исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге эчтәлектәге 70,71 пунктлар өстәргә:

| т/б | Милек атамасы | Мөлкәтнең урнашу урыны | Мәйданы (кв. м.) | Җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|---|---|---|---|---|
| 0 | Торак булмаган бина | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Архангел Бистәсе авылы, Бакча ур., 50 А й. | 288,2 | 16:31:010104:46 |
| 1 | Торак булмаган бина | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Чаллы Башы авылы, Мәктәп ур., 46 й. | 1021,1 | 16:31:040303:69 |

2. Әлеге карарны вакытлы матбугат басмасы - «Яңа Чишмә хәбәрләре» («Шешминская новь») газетасында https://novoshishminsk.ru, «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының

рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов